**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 август № 599

г. Казань

2015 елда гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 елда гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар бирү турында» 2015 ел, 19 июнь, 609 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елда гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\599.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 15 август, 599 нчы
карары белән расланды

2015 елда гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип 2015 елда гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне яхшырту максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бүтән бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчаны (алга таба – акча) файдалану механизмын билгели.

2. Акча Татарстан Республикасы бюджетының түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру белән бәйле чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә юнәлдереләләр:

гражданның гомере кыскаруга яки инвалидлыкка китерә торган тереклек эшчәнлеге өчен куркыныч һәм хроник прогрессив сирәк (орфан) авырулар исемлегенә кертелгән авыруларны дәвалау өчен дару препаратлары белән тәэмин итүне оештыру өлешендә;

Татарстан Республикасы территориясендә халыкның аерым төркемнәрен, амбулаториядә дәвалаганда дару препаратлары табиблар рецептлары буенча түләүсез бирелә торган онкологик авырулар белән җәфаланучы гражданнарны кертеп, түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасы кысаларында дару препаратлары белән тәэмин итүне оештыру өлешендә.

3. Акчаны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тота.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен сатулар, товарлар, эшләр, хезмәтләр өлкәсендә федераль законнар нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү өчен дәүләт заказын урнаштыру һәм дару препаратларын сатып алуны тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән бүтән бюджетара трансфертлар килү турында мәгълүмат алганнан соң соңгысына билгеләнгән тәртиптә финанслауның чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерүгә чыгым тәртибен тапшыра.

6. Финанслауның җиткерелгән күләмнәре чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең акча килү һәм дәүләт заказын урнаштыру

нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләре нигезендә әлеге акчаны дәүләт шартнамәләре (килешүләре) төзелгән оешмаларга күчерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы 2015 елның 10 декабреннән соңга калмыйча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча әлеге Тәртипнең 2 пунктында каралган максатларга финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып бүтән бюджетара трансфертлар торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап тапшыра.

8. Акчаны максатчан файдаланмау бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.

9. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләнә.

F:\KARAR\2015\599.docx